ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

2023 елда полиция эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры хисабы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елда полиция эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры хисабын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары белән бергә «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысаларында комплекслы чараларны гамәлгә ашыруны дәвам итәргә.

2.2. 2024 елда Татарстан Республикасында Россия Федерациясе Президентын, җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны әзерләү һәм үткәрү, федераль проектлар чараларын, «Киләчәк уеннары» халыкара мультиспорт турнирын, «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum 2024» XV халыкара икътисадый форумын, БРИКС илләренең спорт уеннарын, «Kazan Digital Week – 2024» халыкара форумын, XVI Халыкара БРИКС дәүләтләре башлыклары форумын, башка массакүләм чараларны уздыру чорында җәмәгать тәртибен һәм иминлекне тәэмин итәргә.

2.3. Татарстан Республикасы гавами хакимият органнары, иҗтимагый берләшмәләр, традицион конфессияләрнең дини оешмалары, милли-мәдәни автономияләр белән бергә экстремистлык, диверсия һәм террорчылык эшчәнлегенә, бигрәк тә аеруча мөһим инфраструктура объектларына һәм яшәүне тәэмин итү объектларына карата, каршы көрәш өлкәсендә чараларны, ихтимал булган милләтара конфликтларны булдырмау чараларын үткәрүне дәвам итәргә.

2.4. Татарстан Республикасы шәһәрләрендә һәм башка торак пунктларында җәмәгать тәртибен тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны үткәрүне, шул исәптән гражданнар оборонасы өлкәсендә чаралар үткәргәндә

Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларыннан килгән зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе белән бергә, дәвам итәргә.

2.5. Чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар арасында законсыз миграциягә һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш максатында Татарстан Республикасында миграция вәзгыятен тикшереп тору өлешендәге эшне дәвам итәргә.

2.6. Мәгълүмати технологияләрдән файдаланып кылына торган җинаятьләрне профилактикалау механизмнарын камилләштерү чараларын күрергә.

2.7. Балигъ булмаганнарны җинаять эшчәнлегенә тартуга каршы көрәш максатында алар арасындагы хокук бозуларны профилактикалау эшен көчәйтергә.

2.8. Массакүләм мәгълүмат чараларында гражданнарның шәхси иминлеге, аларның акчаларын һәм мөлкәтен саклау мәсьәләләрен аңлата, хокук бозуларның хокукый нәтиҗәләре һәм асоциаль тәртипнең рөхсәт ителмәве турында мәгълүмат бирә, шулай ук халыкта эчке эшләр органнары эше хакында уңай фикер формалаштыра торган материаллар урнаштыру эшен дәвам итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру һәм аны үз вакытында финанслау эшен дәвам итүне тәкъдим итәргә.

4. Җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

4.1. Муниципаль берәмлекләр территорияләрендә хокук саклау органнары белән җәмәгать тәртибен саклауны һәм гражданнарның иминлеген оештыру буенча хезмәттәшлекне активлаштырырга.

4.2. Җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларының административ хокук бозуларны ачыклау һәм тиешле беркетмәләр төзү эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттырырга.

4.3. Халык дружиналарының нәтиҗәле эшен тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне активлаштырырга, шул исәптән өстәмә халык дружиналарын булдыру мөмкинлеген карарга.

4.4. Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашучы затларны бүләкләү эшен дәвам итәргә, аларга премия бирү мөмкинлеген карарга.

4.5. Хокук саклау юнәлешендәге (хокук бозуларны профилактикалау, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, экстремистлык һәм террорчылык күренешләренә каршы көрәш өлкәләрендәге) муниципаль программаларны гамәлгә ашыруны һәм аларны үз вакытында финанслауны, шулай ук әлеге программаларның эчтәлеген «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасы нигезләмәләрен исәпкә алып актуальләштерүне тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтыновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 15 феврале
№ 2335-VI ДС